**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**III чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**III созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
от 15.04.2019 ел

**РЕШЕНИЕ**
№37-14

Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль милек исемлегенә кергән җир кишәрлекләренә, сатуларны үткәрмичә аренда килешүләре төзегәндә аренда хакын исәпләү өчен кадастр бәясе ставкалары процентларын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Актаныш муниципаль районы Уставы, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.7 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районының депутатлар Советы карар бирә:

1. Актаныш муниципаль районы территориясендә сәүдә уздырмыйча гына җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен төзегәндә муниципаль милектәге җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең процент ставкалары берәмлеген билгеләргә, әгәр дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләре карар кабул ителгән көнгә кадәр биш ел алдан расланган булса::

1.1) җир кишәрлегенең кадастр бәясеннән 0,3 процент күләмендә, әгәр җир участогы мәйданы 100 гектардан артып китсә, авыл хуҗалыгы җитештерүен һәм авыл хуҗалыгы кулланылышын алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрен арендага бирү очракларында;

1.2) җир кишәрлегенең кадастр бәясеннән 1,5 процент күләмендә, әгәр җир участогы мәйданы 100 гектардан ким булса, авыл хуҗалыгы җитештерүен һәм авыл хуҗалыгы куллануын алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрен арендага бирү очракларында;

1.3) торак пунктлар җирләренә кертелгән һәм шәхси ярдәмче хуҗалык өчен файдаланыла торган җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 10 проценты күләмендә;

1.4) торак пунктлар җирләренә кертелгән һәм шәхси торак төзелеше өчен файдаланыла торган җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 20 проценты күләмендә;

1.5) торак пунктлар җирләренә кертелгән һәм бакчачылык өчен файдаланыла торган җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 10 проценты күләмендә.

2. Җир кишәрлегенең кадастр бәясе күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәве, кадастр исәбен алу һәм күчемсез милек дәүләт кадастрын алып бару өлкәсендә башкарма хакимиятнең вәкаләтле

3. Әлеге карарны "Актаныш таңнары" газетасында бастырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән соң үз көченә керә.

5.Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Актаныш муниципаль районы Совет Рәисе Э.Н. Фәттахов